СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №53—54 (7226—7227) | 14 май, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Колхоз җәмгыятькә керде

Ульянов исемендәге колхоз КамАЗ акционерлык җәмгыятенә кергәч 300.000 сумга акция сатып алды. Бу аңа әлеге җәмгыятьнең члены булып торырга һәм аның эшчәнлегендә катнашырга хокуклар бирә. Акция ияләренә билгеле өстенлекләр дә каралган: хуҗалык предприятие продукциясен—КамАЗ автомобильләрен, запас частьләрне льготалы шартларда алырга хокуклы. Моннан тыш акция өчен ел саен 5 процент күләмендә дивиденд түләнә.

# КПСС райкомында очрашу

9 май көнне, хәрби-якташларга куелган һәйкәл янында митинг тәмамлангач, КПСС райкомында 54 нче гвардия-укчы дивизия ветераннары белән очрашу булды. Очрашуда партия һәм совет работниклары катнашты.

КПСС райкомының беренче секретаре, халык депутатларының район Советы председателе, ТССР халык депутаты иптәш Х. Х. Морадыймов ветераннарны Бөек бәйрәм—Җиңү көне белән кайнар котлады һәм аларга сәламәтлек, хәерле тормыш, олы бәхет, сәламәтлек теләде. Аннан соң район хезмәт ияләренең бүген нинди мәшәкатьләр белән яшәүләре турында сөйләде. Бездә, диде ул, төрле милләт кешеләре—татарлар, руслар, чувашлар һәм башка милләт халыклары дустанә яшиләр. Шәһәр белән авыл арасында үзара ярдәмләшү һәм үзара аңлашу хөкем сөрә.

Хәлил Хәмзиевич хәл ителергә тиешле проблемаларга да тукталып үтте.

Очрашуда катнашкан сугыш һәм хезмәт ветераннары шәһәр һәм район тормышына кагылышлы, патриотик тәрбия мәсьәләләрен күтәрделәр. Районның социаль-экономик хәле, хуҗалык итүнең яңа ысуллары турында эчкерсез сөйләшү алып барылды.

Кунакларның сорауларына Х. Х. Морадыймов тулы җавап бирде. Ә кунакларга ветераннар советы, районда тормыш дәрәҗәсе нинди булуы турында белү кызыклы иде. Шул ук вакытта Хәлил Хәмзиевич район җитәкчеләренең халык белән ел саен шәһәр микрорайоннарында «Ачык хатлар» көннәре үткәрү, мондый очрашулар халык белән уртак тел табарга, фикерләрне уртаклашырга, бергәләп хәрәкәт итү программасын эшләргә һәм тагын бик күп яңалыкларны ачарга ярдәм итүе турында бәян итте.

Одессада яшәүче отставкадагы полковник П. Г. Кариков яшьлегенең дәһшәтле елларга туры килүе, дуслары турында сөйләде, күп еллардан бирле бергә сугышкан иптәшләрен эзләү белән шөгыльләнүен әйтте. Иптәш Кариков Норлатта 9 май бәйрәме алдыннан булган очрашу истәлеге турында бик мавыгып сөйләде, аңа Норлат халкы, театрлаштырылган күренеш бик ошаган. «Барысы да, партия райкомы бинасы янындагы мәйданда уздырылган тамаша да, эчкерсез каршылау чын йөрәктән, зур теләк белән эшләнгәнлеге сизелеп тора,—диде ул. Ул барлык ветераннар исеменнән район һәм шәһәр җитәкчеләренә кайгыртучанлык күрсәтүләре һәм шушындый әйбәт очрашу оештырулары өчен рәхмәтләрен белдерде.

Очрашуда шулай ук мәскәүле А. П. Андрианов, КПССның Октябрь район комитетының элеккеге беренче секретаре Г. К. Гыйматдинов, партия райкомы секретаре А. А. Коростелев һәм башкалар чыгыш ясады.

Очрашуда кунакларга җир йөзендә тынычлык өчен көрәштә батырлыклар күрсәтүләре өчен иң җылы сүзләр һәм зур рәхмәтләр әйтелде, аларга тере чәчәкләр, Норлат шәһәре эмблемасы билгеләре, истәлек бүләкләре тапшырылды.

**Е. ИЛЮШКИНА.**

# *Бер үк хисләр, кичерешләр белән*

Рәсемнәрдә безнең фотохәбәрчебез Н. Азизов Норлат шәһәрендә Бөек Җиңүнең 46 еллыгын бәйрәм итүне фотога төшереп алган.





Җиңү китергән 1945 елның кояшлы мае елдан-ел ерагая бара. Әмма Җиңү көненең мәгънәсе моннан тоныкланмый, төссезләнми. Һәлак булган якташларыбыз хөрмәтенә куелган һәйкәл янына яше дә, карты да җыела. Өлкән буын кешеләрен бирегә хәтер һәм әрнүләр тартса, яшьләрне шатлыклар һәм киләчәккә планнар китерә. Кара, солдат,—җир яшәрә, синең Ватандашларыңның балалары үсә. Димәк, син илнең киләчәген саклап тикмәгә генә сугышка кермәгәнсең, нәселең сине ничек зурлый.

Әнә алар, тыгыз стена булып торалар. Бу матәмтантаналы минутларны һәркем үзенчә кичереп тын калган. Һәйкәл веноклар, гирляндалар, чәчәк букетларына күмелгән. Әмма—бу ни? Тынлы оркестрның бакыр тавышына яңа авазлар өстәлә. Тигез рәт булып атлаучы ветераннар күкрәгендәге орден-медальләр чыңы икән бу.

Әйе алар елдан-ел кимиләр. Хәтер әле бер, әле икенче йөзне күңелдә яңарта, һәм кинәт аңлыйсың: алар бит юк инде, аларның гомер юлы өзелгән. Һәм кинәт йөрәкне чеметеп искә төшә—алардан иң мөһиме турында сорарга, бер иркенләп сөйләшеп утырырга да өлгермәгәнбез бит!

Бәхеткә, ветераннар исән әле. Әнә алар беренче рәтләрдә торалар. Бер минутлык тынлык, ветераннар чәчләренә бәс сарган башларын мәңгегә яшь калган кордашлары алдында ияләр һәм күңелләреннән генә алар белән сөйләшәләр: без дөрес яшәдекме, сез васыять иткәннәрне үтәп җиткердекме икән? Тынлыкны бозып салют залпы яңгырый. Күңелләр кузгала, тәннәрдән салкынлык үтә. Бу мизгелдә төркем—бербөтен: бер үк хисләр, бер үк әрнү, бер үк шатлык берләштерә аларны.

Өч яшьләр чамасындагы малай этисе җилкәсенә бик җайлап урнашкан. Ул игътибар белән театрлаштырылган тамашаны күзәтә.

Десантчылар киемендәге егетләр осталыкларын күрсәтә башлагач, кинәт сорап куя:

—Эти, тагы сугыш буламы әллә?

Әтисенең җавабы туры һәм кыска:

—Белмим, улым.

—Әтием, мин бу бабайларны бик әйбәт истә калдырырмын, үскәч аларны яратырмын.

—Әйе, улым, синең бабаң, дәресрәге, бабаңның әтисе дә сугышта үлде бит.

—Ә ул нинди иде?

—Алар кебек үк бик әйбәт, шәфкатьле, шат күңелле иде.

Әйе, ветераннар безне күп нәрсәгә өйрәтә алалар әле. Оптимизмга, тормышны сөяргә. Бик авыр сынау үткән бу буын җыр, күңел ачу кебек нәрсәләрне дә онытмаган. Менә нәрсәгә өйрәнәсе бар безгә дә!

Ә Җиңү бәйрәме дәвам итте. Андагы ачышларның берсе—бактың исә, бездә байтак бию коллективлары бар икән. Алар башкаруында илебез халыклары биюләре мәңгелек ут янында алыштыргысыз вахтада торучы солдат аяк очындагы бәйрәм венокларыдай үрелделәр.

**Г. ХӘЛИУЛЛИНА.**

# Уңыш өчен көрәш

Быелгы язгы чәчү җирләрнең тигез өлгермәве белән катлауланды. Шулай да колхозда 1300 гектар җир культивацияләнде, 767 гектарда уҗым арышы туклandырылды һәм тырмаланды.

126 гектарда азык катнашмасы, 162 гектарда солы, 143 гектарда борчак чәчелде.

Язгы чәчүдә Сергей Сибулатов һәм Михаил Ивашкин җитәкчелегендәге арендa звенолары үзара ярышып эшлиләр. С. Сибулатов звеносыннан Андрей Сибулатов, Виктор Булатов, Валентин һәм Василий Таймуллиннар, Алексей Михайлов, Павел Убамзаров, Михаил Ивашкин звеносыннан Сабир Сафиуллин, Мансур Насыйбуллин, Рифкать Вәлиуллин кебек механизаторлар бүгенгесе көндә уңыш өчен армыйталмый хезмәт итәләр.

**Т. ДЕРБЫШЕВ.**

● *КПСС райкомы пленумы алдыннан*

# Практик ярдәмгә игътибар кимемәсен

1990 ел КПСС тарихында иң кискен, катлаулы ел булгандыр дип саныйм. Күппартиялелек гамәлгә керде, партиянең үз эчендә дә демократик канат барлыкка килде. КПССның XXVIII съезды алдыннан, аның барышында һәм соңрак та аңа карата һөҗүм, барлык кимчелекләр өчен аны гаепләү абруена нык сукты. Ул чакта партия сафларыннан чыгучылар да байтак булды.

Әмма безнең партия оешмасын әлеге давыл читләтеп үтте. Моны мин шуның белән дә аңлатам: күп КПСС членнары җәмәгать интереслары турында кайгырталар, иҗтимагый яктан активлар, күмәк эш өчен янып яшиләр, башкаларга шәхси үрнәк булып торалар. Токарь Борис Бокарев, дуңгыз караучы Владимир Абрамов үзләренә йөкләтелгән эшне намус белән башкаралар. Инженер Александр Кульметьевка берәр бурыч йөкләтелгән икән, аның үтәләчәгенә шик тотмаска мөмкин. Ветераннар советы рәисе Алексей Ильин, пенсионер Иван Немов өлкән яшьтә булуларына карамастан җәмәгать эшендә актив катнашып киләләр.

Боларны мин ни өчен китердем: партоешманың күп коммунистлары үзләренә йөкләтелгән бурычны төгәл үтиләр, колхоз производствосы белән тыгыз элемтәдә торалар, килеп туган кыенлыкларның вакытлы булуын, алардан арыну өчен ныгытып эшләү кирәген яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә аерым коммунистларның хаталары, ялгышларының тулаем партиягә тап булуы белән килешмәделәр. Аерым урыннарда КПСС сафларыннан чыгу барган бер очракта да бездә мондый фактлар булмады. Димәк, безнең арада шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгыртып керүчеләр булмаган дигән сүз бу.

Минемчә, партия тарихында кризислы момент узылды шикелле. Хезмәт кешеләре демократларның күбесе телгә генә оста икәнлеген күрде, көндәлек туган икеләнүләрдән арына бара. Бу авыл хезмәтчеләренең партия курсын яклавында да ачык чагыла: халык безнең белән теләктәш.

Партоешманың, аның бюросының эшчәнлегеннән, секретарь буларак, мин канәгать түгел әле. Башка партоешмаларга хас кимчелекләр—пассивлык безгә дә хас. Массаларны үзенә ияртеп бару, лидер ролен үтәү өчен эш стилен безгә дә тамырдан үзгәртергә кирәк. Бу мәсьәләдә коммунистларның шәхси үрнәге зур роль уйный. Аерым коммунистлар шул мәсьәләдә, турыдан әйткәндә, аксаталар әле: эштә дә сүлпәннәр, коммунист буларак та иҗтимагый-сәяси тормыштан читтә калалар. Бу бөтен халыкның активлыгы, ил, район хәлләре белән даими кызыксынган бер заманада гафу ителми, алгы сафта барырга кирәк безгә бүген.

Партоешманың активлыгын күтәрү мәсьәләсендә бер принципны гамәлгә ашыруны мөһим саныйм: ул аның мөстәкыйльлеген үстерүгә бәйле. Соңгысы хакында күп сөйләсәк тә, чынбарлыкта практик адымнарыбыз аз һәм, яшеренбатырын түгел, бу юнәлештә ниләр эшләргә кирәген үзебез дә белеп бетермибез әле. Бу мәсьәләдә райкомның оештыру-партия эше һәм партия оешмалары эшчәнлеген яңарту комиссиясенең практик ярдәме, конкрет булышлыгы безгә этәргеч булыр иде.

Һәм бу уңайдан тагын бер моментка тукталып узу урынлы саныйм. Хәзер без иске алым, формалардан баш тартабыз, һәр нәрсәне яңача оештырылырга тиеш дип кабул итәбез. Бу бер яктан дөрес. Тик икенче ягы игътибарга алынып җитми, минемчә. Партия работникларының күбесе яңарган бүгенге моментта эшне аларга гына йөкләтү, мөстәкыйльлеккә ишарәләп практик ярдәмгә әһәмиятне кимету иртәрәк дип уйлыйм. КПСС райкомы комиссияләре ярдәме көчәя төшсен иде. Бу башлангыч партоешмаларның массаларга йогынты көче үсүгә булышыр.

**П. ИВАНОВ,**
«Знамя Октября» колхозы партия оешмасы секретаре.



**Фоат Ихтисамов—«Октябрь» ремонт-техник предприятиесендә 7 еллап эшли инде. Техниканы яратучы эшнең рәтен белүче бу шофер соңгы вакытта КамАЗ машинасында авыл хуҗалыгы йөкләре ташый. Быел язын ай дәвамында хуҗалыкларга чәчүлек орлык ташуда эшләде. Көнлек нормасын 110—120 процентка үтәп килде.**

**Ә бу көннәрдә Фоат ремонт белән шөгыльләнә. Язгы-җәйге мәшәкатьләр машинаның һәрчак сугышчан әзерлектә булуын таләп итә шул.**

**Рәсемдә: шофер Фоат Самат улы Ихтисам[illegible]**

# Киләсе очрашуга кадәр

Соңгы көннәрдә күкрәкләренә орден-медальләр таккан кунаклар—51 нче аерым укчы бригаданың 21 сугышчысы шәһәрдә эшчеләр, мәктәп укучылары, район авыллары халкы белән очрашуларда булдылар. Алар Җиңүнең 46 еллыгына багышланган тантаналы кичәдә, митингта, аннан театрлаштырылган тамашада катнаштылар, КПСС райкомында очрашуда булдылар, үзәк стадионда спорт бәйрәмен карадылар, ә кичен кафега җыелдылар. Инде менә—4 көнлек тыгыз программа артта, кунаклар сугышчан дуслары белән, шәһәр белән, яңа танышлары белән хушланалар. Ә күңелдә—тәэсирләр, тәэсирләр.

Мөгаен, иң күп тәэсирләр бригаданың формалашкан төбәгеннән—Норлаттан тупланган сугышчылардадыр. Алар ул чактагы станция белән хәзерге Норлатны чагыштыралар, таныш сукмакларны, таныш йортларны эзлиләр.

Югары Норлат авылында булганда Михаил Алексеевич Майраков элекке мәктәп директоры Т. Г. Гыймадиев белән шулай хатирәләргә бирелеп утырды. Искиткеч: ветеран авылның һәр сукмагын, һәр күллеген әйбәт хәтерли икән.

Истәлекләр Н. П. Снежкинны да яшьлегенә алып кайттылар. Ул шул чорда туганнары яшәгән йортны, фатирларны эзләп тапты, кыенсынып булса да ишек какты һәм гаҗәеп хәлгә тап булды:һәр ике йортта да аларны (ул туганы белән иде) күптәнге танышлар, якын туганнардай каршы алдылар, табын кордылар. Шул түгелме кунакчыллык, шул түгелме кешелеклек? Гомумән, Николай Павлович бу очрашулардан гаҗәеп канәгать.

Искиткеч эчкерсезлек, искиткеч дустанә аңлашу, югары культура һәм хөрмәт күрсәтелде безгә,—ди ул—моны хәтта сүз белән аңлату да мөмкин түгел.

Бу— очрашуга җыелганнарның һәммәсенең уртак фикере. Һәммәсе алдан уйланган: очрашулар да, ял программасы да, көнкүреш ваклыклары, туклану да, транспорт та.

—Ветераннарга шундый хөрмәт, ихтирамны күрү чиксез дулкынландырды безне,—диләр кунаклар беравыздан. Аннан һәркем үзе очрашкан коллектив турында сөйләп китә. Ә очрашулар аз булмады. Шәһәр мәктәпләреннән тыш НГДУ, НУРБ, машина төзү заводы, Хафизов исемендәге колхоз, хуҗалыкара берләшмә коллективларында күрешүләр бик җылы шартларда үттеләр. КПСС райкомында очрашу вакытында ветеран кунаклар районның үсеш перспективасы белән тирәннән кызыксындылар, илдәге вакыйгаларга мөнәсәбәтләрен белдерделәр. Ветераннар әле сафта, алар актив тормыш белән яшиләр икән, аралашудан шундый фикер ныгыды бездә.

Инде менә алар соңгы тәэсирләрен сөйлиләр, адреслар алышалар. Минскидан М. А. Майраков, Казаннан Ш. С. Садыйков, Макеевкадан А. И. Яковенко, Аксубай районының Тимошкино авылыннан П. И. Литта, Ростовтан О. М. Делянова һәм башкалар, һәм башкалар.

—Ун елдан тагы бирегә килергә насыйп итсен,—диләр алар китәр алдыннан.

—Юк, безнең яшьтә андый срок билгеләү куркыныч, әйдәгез, 5 елдан,—дип төзәтмә кертәләр шунда ук.

—Ә бәлки Җиңүнең 50 еллыгына җыелырбыз?

Фикерләшүдән сизәбез: Норлат ошаган, аның кунакчыл хуҗалары күңелләренә хуш килгән, шуңа бу юмарт җиргә тагы һәм тагы киләселәре, хатирәләр иленә кайтасылары килә. Шуңа перронда соңгы хушлашу сүзе бик өметләндергеч яңгырады:

—Сау булыгыз! Киләсе очрашуга кадәр!

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**


# ШӘХСИ СЕКТОРДАН СӨТ САТУ МӘГЪЛҮМАТЛАРЫ

**Беренче багана—авыл Советлары, икенче—1991 елның I ярты елына җиткерелгән план, өченче—аның 1991 елның 12 маена, дүртенче—узган елның шул чорына сатылган сөт (центнерларда), бишенче—1991 елда, алтынчы—1990 елда бер сыерга сатылган сөт, җиденче—алар арасындагы аерма (килограммнарда).**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Андреевка | 301 | 43 | 98 | 41,3 | 84 | —42,7 |
| Богдашкино | 307 | 49 | 66 | 46,2 | 66 | —19,8 |
| Киекле | 1183 | 94 | 495 | 23,0 | 121 | —98,0 |
| Иске Чаллы | 956 | 291 | 544 | 88,2 | 166 | —77,8 |
| Яңа Иглай | 925 | 205 | 671 | 64,3 | 211 | —146,7 |
| Кормыш | 890 | 497 | 824 | 161,9 | 289 | —127,1 |
| Урта Камышлы | 603 | 192 | 171 | 92,3 | 84 | +8,[illegible] |
| Егоркино | 710 | 102 | 395 | 41,6 | 151 | —109,4 |
| Якушкино | 681 | 141 | 447 | 60,0 | 194 | —134 |
| Биләр Озеро | 637 | 32 | 133 | 14,5 | 64 | —49,5 |
| Бикүле | 1183 | 80 | 436 | 19,6 | 109 | —89,4 |
| Аксумла | 577 | 208 | 141 | 104,5 | 75 | +29,5 |
| Фома | 841 | 180 | 542 | 62,1 | 190 | —127,9 |
| Мамык | 342 | 54 | 66 | 45,8 | 66 | —20,2 |
| Сәләнгеш | 421 | 158 | 317 | 109,0 | 220 | —111 |
| Елаур | 722 | 104 | 157 | 41,8 | 61 | —19,2 |
| Тимерлек | 415 | 118 | 117 | 82,5 | 81 | +1,5 |
| Иске Әлмәт | 615 | 171 | 289 | 80,7 | 138 | —57,3 |
| Кычытканлы | 493 | 411 | 568 | 241,8 | 340 | —98,2 |
| Әмзә | 664 | 396 | 549 | 172,9 | 240 | —67,1 |
| Колбай Мораса | 655 | 93 | 188 | 41,2 | 83 | —41,8 |
| Заречный | 369 | 16 | 23 | 12,6 | 18 | —5,4 |
| Төрнәс | 464 | 61 | 88 | 38,1 | 62 | —23,9 |
| Чулпан | 739 | 86 | 209 | 33,7 | 85 | —51,3 |
| Тумба | 264 | — | | | | |
| Югары Норлат | 410 | 303 | 250 | 216,4 | 194 | —22,4 |
| Район буенча | 16367 | 4092 | 7784 | 72,5 | 140,4 | —67,9 |

## Радиация фоны—нормаль

Октябрь районының санитария - эпидемиология станциясе түбәндәгене хәбәр итә: хәзерге вакытта шәһәрдә радиация фоны 5—8 мкр-сәгать тәшкил итә. Бу халыкны борчырлык түгел. Ул безнең якның табигый фонына тәңгәл килә.



**Бу рәсем район культура йорты фойесында моннан 2 ел артык элек төшереп алынган иде. Фома авылыннан сугышка киткән һәм солдат вазифасын намуслы үтәп җиңү яулауга лаеклы өлеш керткән Р. Сафин (сулдан уңга), В. Фәйзетдинов, Н. Галимов, чулпанлы Г. Җиһаншин турында күпләп язарга мөмкин булыр иде. Ветераннар сугышта да, аннан кайткач туган авылларында да хезмәтнең алгы сызыгында булдылар, якташларына эштә үрнәк күрсәттеләр.**

**С. Казакова фотосы.**

*Синең кешеләрең, авыл*

# Коллектив бердәм эшли

Сөйләргә теләгәнем — «Большевик» колхозының Аксумла товарлыклы-сөтчелек фермасы коллективы турында. Бер караганда, биредә яңалык итеп күрсәтерлек, өлге итеп күккә чөярлек бернинди гадәттән тыш нәрсә юк. Ферма бинасы иске, капиталь ремонт кирәк. Шул сәбәптән сөтүткәргеч тә юк, азык тарату җайланмасы кертелмәгән. Шундый шартларда зарланырлар да эшне баштан ташларлар иде кайберәүләр булса. Әмма юк, биредә андый кешеләр җыелмаган. Шундый шартларда да коллектив стабиль сөт җитештерә, үз алдына куйган бурычны уңышлы үтәп килә. Узган ел биредә һәр сыердан 3698 килограмм сөт савылды, бу колхоз буенча уртача күрсәткечтән 233 килограммга артыграк. Сөтнең майлылыгы, сыйфаты да югары. Быелның I кварталын коллектив янә җиңүчеләр сафында төгәллләде. Биредә һәр сыердан 867 килограмм продукция җитештерелде, бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 18 килограммга, уртача колхоз күрсәткеченнән 38 килограммга югарырак. Бүген дә фермада бер сыерга көнлек савым 12,9 килограмм тәшкил итә. Күрәсез, күрсәткечләр һич начар түгел. Шулай да, хикмәте нәрсәдә соң мондый уңышларның?

Минемчә, аның сере гади: кешеләрдә. Ферма коллективы үтә дә намуслы, эшчән терлекчеләрдән тупланган. Сыер савучылар Е. Григорьева, З. Акмуллина, Л. Леонтьева, В. Парукова, Ю. Григорьева күп еллар эшләп тәҗрибә туплаган кадрлар, түземле остазлар да. Терлекчеләр арасында да шундый намуслы работниклар аз түгел. 30 ел терлекчелектә эшләгән Аркадий Ильич Парфенов, Виталий Акмуллин, Евгений Паруков та үз эшләренә гаять җитди карыйлар. Ә боларның һәммәсе белән яшь шофер Александр Артемьевич Егоров җитәкчелек итә. Дөрес, җитәкчелек стажы бик аз әле аның. Аңа кадәр биредә терлекче булып эшләде, хезмәте белән иптәшләренең хөрмәтен һәм ышанычын яулады. Коллектив аны үз җитәкчесе итеп бертавыштан диярлек сайлады. Хәзер мөдир һәм коллектив үзара килешеп эшлиләр. Ышанабыз: яшь мөдир фермадагы эшләрне тагы да яхшыртыр, күрсәткечләрне даими итәр.

Әлбәттә, уңышка китергән сәбәпләр тагы да бар. Көтүне яңарту белән даими шөгыльләнүнең дә файдасы зур. Узган ел 70 баш кара чуар токым таналар кайтарылды. Азык базасы да мул иде. Үткән ел аны һәр шартлы терлеккә 39 азык берәмлеге әзерләдек—болар һәммәсе безнең эшебезгә зур плюс, әлбәттә. Әмма бу фермада эшләүче апайлар хезмәтенең ни дәрәҗәдә авыр булуы безне борчымый дип уйлау хата булыр иде. Уңышлар аларның исәнлеге бәрабәренә килүен дә аңлыйбыз. Шуңа да капиталь ремонт ясау, универсаль сөтүткәргеч сузу кебек нәрсәләр турында колхоз җитәкчелеге бүгеннән уйлана. Аны һичшиксез сузмаска, якын арада башкарырга кирәк.

Хәзер коллектив җәйләү чорына әзерләнә. Бу бригаданың стационар җәйге лагере бар, анда универсаль сөтүткәргеч куелган. Техник-төзүче Николай Дмитриевич Яковлев җитәкчелегендә пенсионерлардан тупланган звено аны төзәтеп чыкты, лагерь малларны кабул итәргә бүгеннән әзер.

Икенче бригадада исә яңа лагерь төзелә, аны сезонга өлгертү өчен тырышалар. Җәйге мул сөт чорына шундый ныклы әзерлек, кәеф белән керү бик мөһим. «Большевик» колхозының беренче фермасы коллективы моны яхшы аңлый.

**Н. АБРАМОВ,**
«Большевик» колхозы зоотехнигы.

# Илләргә иминлек теләп

8 май көнне Хафизов исемендәге колхозның сугыш һәм хезмәт ветераннарының шәһәребез кунаклары —51 нче аерым укчы бригаданың элекке сугышчылары Михаил Алексеевич Майраков, Дмитрий Семенович Руденко, Алексей Иванович Яковенко, Николай Павлович Снежкин, Николай Дмитриевич Андрющенко, Петр Григорьевич Забирко белән тантаналы очрашуы булып үтте. Очрашуны колхоз рәисе Х. Х. Гатин ачып җибәрде. Ул хөрмәтле ветераннарны күп фаҗига-михнәтләр аша үзләре яулап алган Җиңү бәйрәме белән тәбрик итте.


Кунаклар һәм хуҗалар арасында бәйрәм уңаеннан эчкерсез әңгәмә өстәл артында дәвам итте. Сөйләшәсе сүзләре күп, фикерләре уртак иде ветераннарның. Колхозның партоешма секретаре Минвәли Исмәгыйлевич Җәлалов колхозның сугыш һәм хезмәт ветераны коммунист Петр Ильич Васильев турында сөйләде, аңа «КПСС сафларында 50 ел» дигән билге һәм таныклык, кыйммәтле бүләк тапшырылды.

Очрашуга җыелучылар сугыштан кайта алмый калганнарны бер минутлык тынлык белән искә алдылар һәм алар истәлегенә Кормыш, Чуваш Мәнҗесе, Чишмә авылларындагы һәйкәлләргә веноклар куйдылар.

Тантанада катнашучылар илләргә иминлек, тынычлык теләп таралыштылар.

**Р. ШӘЙХУЛЛИНА.**





Тәлгать Маняпов—«Үрнәк» колхозының яшь һәм уңган шоферларыннан берсе. Берничә ел элек армиядән кайтып эшкә керешкән иде ул. Кайсы тармакка җибәрсәләр дә карусыз эшләде, тырыш булды. Быелгы язда Тәлгать «Рассвет» совхозыннан чәчүлек орлык алмаштыруда эшләде, көнлек нормасын 110 процентка кадәр җиткерде.

Һәрчак шулай. Тәлгать кайда гына эшләсә дә сынатмый, үзенә тапшырылган эшне намус белән башкара.

Рәсемдә: Т. Маняпов рейска чыгар алдыннан.

# *КЫР ЭШЛӘРЕ НИЧЕК БАРА?*

**Беренче багана—хуҗалыклар исемнәре, икенче—сабан культуралары чәчү планы, өченче—1991 елның 13 маена чәчелгән мәйдан (гектарларда), дүртенче—башкарылган эш (процентларда).**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 1810 | 1428 | 79 |
| Ульянов исем. | 1942 | 1065 | 55 |
| «Правда» | 1796 | 589 | 33 |
| «Восход» | 1594 | 1208 | 76 |
| Мичурин исем. | 1574 | 1200 | 76 |
| «Россия» | 1448 | 1093 | 75 |
| Хафизов исем. | 1311 | 808 | 61 |
| «Путь к коммунизму» | 2368 | 1240 | 52 |
| Муса Җәлил | 1150 | 671 | 58 |
| «Родина» | 1147 | 410 | 36 |
| «Игенче» | 2070 | 1110 | 54 |
| «Большевик» | 1483 | 1019 | 69 |
| «Заветы Ильича» | 1546 | 1115 | 72 |
| «Знамя Октября» | 1623 | 1010 | 62 |
| «Алга» | 2760 | 1858 | 67 |
| «Комбайн» | 2211 | 1378 | 62 |
| XXI партсъезд исем. | 2582 | 2070 | 80 |
| «Татарстан» | 1289 | 957 | 74 |
| «40 лет Победы» | 1349 | 748 | 55 |
| «Чишмә» | 1944 | 1050 | 54 |
| «Таң» | 991 | 667 | 67 |
| «Москва» | 1551 | 1017 | 65 |
| «Үрнәк» | 745 | 665 | 89 |
| «Лесная поляна» | 338 | 208 | 61 |
| «Кондырча» | 772 | 549 | 71 |
| Кузнецов исем. | 1596 | 911 | 57 |
| «Заря» | 1275 | 969 | 76 |
| «Чирмешән» | 784 | 421 | 54 |
| «Ленинский путь» | 1387 | 985 | 71 |
| «Беренче Май» | 2066 | 1276 | 62 |
| «Төрнәс» совхозы | 2169 | 1276 | 59 |
| «Мамык» совхозы | 1670 | 1300 | 78 |
| «Рассвет» совхозы | 2637 | 2087 | 79 |
| «Сөлчә» совхозы | 1300 | 720 | 55 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 840 | 327 | 39 |
| «Яшь көч» | 613 | 545 | 85 |
| Район буенча | 55761 | 35950 | 64 |

# Чәчү алдынгылары

Х. Гайнетдинов агрегаты 34 гектарда борчак чәчеп нормасын күпкә узып китте. Хатыйп Хөсәенович 25 елдан артык чылбырлы тракторда эшли, иген игә һәм һәрчак хезмәтен тырышып башкара.

Чәчүдә эшләүче М. Әбделвәлиев агрегаты да ул көнне смена нормасын күпкә арттырып үтәде.

Башка механизаторлар да язгы кыр эшләрен тиз төгәлләү өчен тырышалар. Җир катоклауда Г. Зәйдуллин агрегаты норманы 2,5 тапкыр арттырып үтәде. Культивацияләүдә эшләүче М. Мостафин, И. Саттаров, Ф. Хәсәншин һәм башка механизаторлар да өлгерлек күрсәттеләр.

**Г. САДЫЙКОВА.**
М. Җәлил исемендәге колхоз.

# Беренче җиңү яуланды

Яшь гаиләнең башка чыгып бөтен кирәк-яракны табу мәшәкатьләре чыккан кебек үк,Синдряков исемендәге колхоздан аерылгач «Яшь көч» колхозына да шундый ук кыенлыкларны баштан кичерергә туры килә.

Ел башында халык теләге тормышка ашты.

«Мөстәкыйль яшәп,эшләгәнебезне читкә җибәрмәбез, тормышыбыз бөтенәер»—диештеләр алар. Рәис итеп авылдашлары, озак еллар бригадир булып эшләүче Х. М. Әбделганиевны сайлап куйдылар.

Аерылуы бер хәл: әмма чәчү вакыты якынлаша, хуҗалыкта ни тракторы, ни чәчү агрегатлары җитешми. Алай гына да түгел, элек үзе генә чәчү, язгы кыр эшләрен башкармагач, яшәүнең ул ягы кайгыртылганы да юк иде. Үч иткәндәй чәчү җирләре дә көздән сөрелмәгән, хәтта 300 гектардан салам да җыелмаган килеш калды.

Колхозчылар мондый авырлыклар белән килештеләр, нишлисең тиз генә берни дә төзелми: кайсы кирәк-яракны синдряковлылардан, беришесен «1 нче Май» колхозыннан алып, бердәм рәвештә язгы кыр эшләренә керештеләр.

Биредә чәчүлек җирләре меңгә якын гектарлап тәшкил итә. Кечкенә генә хуҗалык өчен аз дип булмый, чөнки эшче куллар да, техника да җиренә карап бит. Аның каравы, игенчеләр арасында оешканлык, җыйнаклылык хөкем сөрә.

«Яшь көч»нең исеме дә җисеменә туры килә: игенчеләр һәммәсе дә яшьләр. Язгы кыр эшләрендә тырмалаумы, туклындырумы, культивацияләүме бөтен җирдә Исмәгыйль Сабиров, Рәшит Гатин, Владимир Леуков, Хәсән Хәлиуллин, Сәгыйть Вафин әйдәп баручылар булдылар.

Шул ягы уңай булды биредә: урыны шундый булгандыр, җир тиз өлгерде, быел күп кенә хуҗалыклардагы кебек юеш, оешып торучан түгел иде. Шунлыктан чәчүгә дә вакытында керешә алдылар.

Әз-мәз генә бодаен, арпасын, солысын — барысын да чәчәләр. Бер чәчү агрегатында Җәлил Җамалов, чәчкечтәгеләр Илшат Мингалимов, Фәрит Вәлиәхмәтов, Илшат Шәйхиев, икенче агрегат хуҗалары Тәлгать Вафин һәм чәчүчеләр Илгиз Вәлиев, Сергей Сидеряков, Илфат Әхмәтҗанов быел кырда үз бакчаларындагыдай тырышлык күрсәттеләр. Фәрхать Хәлиуллин белән Юныс Исламгалиев чәчүчеләргә үзвакытында орлык ташып тордылар.Нәтиҗәдә егетләр Җиңү бәйрәме алдыннан бөртекле культуралар чәчүне тәмамладылар. «Бөтен эшне колхозчыларның кәефе, эшкә карашы хәл итә»—ди колхоз рәисе Хәсән Минвәлиевич. Бу сүзләр тикмәгә генә әйтелми, әлбәттә. Беренче уңышның ул нәкъ алар тырышлыгы аркасында гына килеп чыгуына нык инанган.

Без килгәндә егетләр сабан культураларын чәчеп, соңгы гектарларны тәмамлап киләләр иде. Кыска гына сөйләшү арасында үзләрен өч тапкыр туклындырып торучылар Алсу Гатина һәм пенсионер Нәҗия Җамалованы мактап телгә алдылар. Гомумән, алар барысыннан да канәгать, әмма тыйнаклар: һич тә мактанырга ашыкмыйлар.

—Кукуруздан кала чәчүне бетерү зур эш,җаваплы эш, әмма «чебешләрне көзен санныйлар», диләр. Без дә уңыш турында көзгә сөйләшербез,—дип, кадерле минутларны әрәм итмичә эш урыннарына ашыктылар.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

